**ИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ СПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

улица К.Маркса, дом 46,
город Чистополь, 422980

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

К.Маркс урамы, 46 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел.(84342) 5-13-38, тел/факс 5-13-38, E-mail: chistay@tatar.ru

№ 20 08.02.2019

Постановление Карар

Чистай муниципаль районы
шәһәр башкарма комитетының
06.03. 2018 елгы 41 нче карары
белән расланган Чистай шәһәре
территориясендә муниципаль торак
контроле өлкәсендә законнарны үтәүгә
тикшерү уздыруның
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Чистай шәһәр прокурорының 31.01. 2019 елгы 02-08-02-2019 нчы протестын үтәү йөзеннән , 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары турында”гы 131 нче Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән “ Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы 294 нче номерлы Федераль закон нигезендә, 2018 елның 27 декабрендә кабул ителгән “Россия Федерациясенең Торак кодексына күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзүне һәм (яки) яңадан планлаштыруны көйләүче нормаларны тәртипкә китерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында”гы 558нче – Федераль закон белән, РФ Торак кодексының 20 нче маддәсенең 4.2 өлеше белән каралган, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы шәһәр башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы шәһәр башкарма комитетының 06.03. 2018 елгы 41 нче карары белән расланган Чистай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле өлкәсендә законнарны үтәүгә тикшерү уздыруның административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.3 пунктның 4нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан дәүләт торак күзәтчелеге органына, муниципаль торак контроле органына аерым алганда, система чарасы белән кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт власте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан кергән мәгълүмат, системада дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органы тарафыннан таләпләрне бозу фактлары турындагы мәгълүматны ачыклау, күп фатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы биналар хуҗаларына һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктату һәм чикләү, торак хуҗалары ширкәтләре, торак, торак- төзелеш яки башка махсус кулланучылар кооперативы булдыру тәртибенә, торак хуҗалары ширкәтләре, торак, торак-төзелеш яки башка махсус кулланучылар кооперативы уставына һәм шундый ширкәт яки шундый кооператив уставына үзгәрешләр кертү тәртибенә, күп фатирлы йортлардагы биналар хуҗаларының күп фатирлы йортлар белән идарә итүгә идарә итүче оешма белән килешү төзү максатында күп фатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлек алып баручы, оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик затны яки шәхси эшмәкәрне сайлау турында карар кабул итү тәртибенә таләпләр, идарә итүче оешма белән күп фатирлы йорттагы уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәт күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару килешүе төзү турында карар, күп фатирлы йорттагы уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәт күрсәтү һәм (яки) эшләр башкаруга әлеге Кодексның 164 нче маддәсенең 1нче өлешендә күрсәтелгән затлар белән килешү төзү турында карар, әлеге килешү шартларын раслау һәм аларны төзү тәртибенә, күп фатирлы йорттагы уртак мөлкәтне карап тоту һәм әлеге йортта уртак мөлкәтне агымдагы һәм капиталь ремонтлауны башкару тәртибенә, күп фатирлы йорттагы биналарны яңадан планлаштыру һәм (яки) яңадан төзүне гамәлгә ашыру тәртибе таләпләрен бозу фактлары турында, идарә итүче оешманың әлеге Кодексның 164 нче маддәсенең 2нче өлешендә каралган йөкләмәләрне бозу фактлары турында, коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган күләмен үзгәртүдә соңгы чик (максималь) индекслар куллану өлкәсендә бозу фактлары турында, коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр) куллануның билгеләнгән нормативының нигезләнмәгән күләме фактлары турында, коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр) куллану нормативы составына таләпләрне бозу, коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр) куллану нормативларын билгеләү шартларын һәм алымнарын үтәмәү, күп фатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм торак бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен бозу, торак биналарны наймга алучыларның социаль файдаланудагы наймга бирелгән йортларда шундый йортлардагы биналарны наймга бирүчеләргә һәм наймга алучыларга карата мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында, социаль файдаланудагы торак фондтагы торак биналарга найм килешүләре һәм торак биналарны наймга алу килешүләре төзүгә һәм үтәүгә, җирле үзидарә органнары, ресурслар белән тәэмин итү оешмалары, күп фатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлекне тормышка ашыручы затлар, гражданнар тарафыннан системада мәгълүматны урнаштыру тәртибенә

таләпләрне бозу фактлары турында. Россия Федерациясе баш дәүләт торак инспекторының Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә бирелгән планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерыгы (әмере) дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органы тарафыннан (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт власте органнары тарафыннан җирле үзидарәнең вәкаләтле органнарына лицензияле контрольне тормышка ашырганда тикшерү үткәрү буенча вәкаләтләр бирелгән очракта) планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора. Күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү прокуратура органнары белән килештерүләрсез һәм тикшерелә торган оешмага планнан тыш тикшерү үткәрү турында алдан хәбәр итмичә үткәрелә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районың рәсми сайтында (http://chistopol. tatarstan. ru. ) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Шәһәр башкарма комитеты
җитәкчесе вазифаларын башкаручы А.В. Сашин.